Степанова Любовь Васильевна,

Россия, Республика Татарстан,

Рыбно-Слобдский район,с. Козяково-Челны

**Судьба мужчины - судьба Родины (на татарском языке).**

Токранов Иван Захар улы 1916 елның 24 августында Татарстан Республикасы Балык бистәсе районы Иванай авылында крестьян гаиләсендә туа. Авылда 7-еллык белем алгач, 1933 елның Алабуга авыл хуҗалыгы рабфагына укырга керә һәм аны 1935 елны уңышлы тәмамлый. Шул ук елны Алабуга укытучылар институтының математика бүлегенә укырга керә. Ләкин тормыш авыр булу сәбәпле, ул укуын ташларга мәҗбүр була.

1936 нчы елның сентябрь аенда РОНО приказы белән Иске Арыш башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнә.

Иван Захарович 1937 елның сентябрь аенда Кызыл армиягә хезмәткә алына. Бөек Ватан сугышында башыннан ахырына кадәр катнаша. Лениннград блокадасының бөтен авырлыкларын үз җилкәсендә татый. Батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнә.

Сугыш беткәч, 1947 елда авылга кайта, экстрен рәвештә Чистай педучилищесында экзамен бирә, аңа башлангыч класс укытучысы исеме бирелә. 1947 елны аны Иванай башлангыч мәктәбенә мөдир итеп билгелиләр.

1950 елның августыннан 1953 елның августына кадәр Күки җидееллык мәктәбендә математика укытучысы итеп билгеләнә. Иванай мәктәбен башлангыч мәктәп итеп үзгәртү сәбәпле, Иван Захарович 1946 елдан шушы мәктәптә 1976 елга кадәр мөдир һәм укытучы булып эшли һәм лаеклы ялга чыга.

Озакка сузылган авырудан соң 72 нче яшендә үлә.

Ул укытучылык эшен җәмәгать эшләрендә актив катнашу белән тыгыз бәйләп алып бара. 29 ел туган колхозында партия оешмасы сыкретаре, пропагандист булып эшли.

Иван Захаровичның семьясы да зур була. Семьяда 4 малай, 5 кыз үсә. Прасковья Матвеевна белән бу балаларны үстерүгә зур хезмәт куялар.

Ул гаятьтә тыйнак, киң күңелле, кешеләрне ярата иде.

Җир йөзендә сокланырлык шактый нәрсә бар. Яшәү дәверендә кешелек тә бихисап гайрәтле хәлләр күргән...

Безнең буын өчен иң сокландырганы Бөек Ватан сугышы елларында Ватаныбыз азатлыгын саклап калган ил сакчыларының батырлыгы. Ә ул нәгъләт сугыш мәңге-мәңгегә бөтендөнья халкы өчен гыйбрәт булып калсын иде. Сугыш утын яңадан кабызучыларга сабак булсын иде.

Ватаныбыз азатлыгын саклаучыларның берсе - авылдашыбыз Токранов Иван Захарович.

...Авыр сугыш очсыз-кырыйсыз фронтларда безнең гаскәрләр өчен әлегә

уңышсыз дәвам итә. Ленинград тулысынча камалышта. Көннән-көн шәһәр халкы, аны саклаучы солдатлар өчен мөмкинлекләр кыенайганнан-кыеная бара. Дошман исә, һөҗүмнең һәртөрле юлын табып кына тора. Бертуктаусыз һава хөҗүме артиллерия уты шуның өстенә самолётлардан ап-ак кар яугандай листовкалар оча. ”Бирелегез сез барыгыз да үлемгә дучар!”. Бу чорда автомобиль взводы командиры кече лейтенант И.Токранов инде шактый сугыш сынаулары үткән була. 1917 елда Кызыл Армиянең Киев хәрби округында ул танк мәктәбендә курсант буларак, хәрби хезмәтен башлый. Аннан, уку уңышлы тәмамлангач, ул - танк командиры. Җитәкчеләре яшь хәрбидә укуга омтылыш, булдыклылык күреп И.Токрановны берничә айдан Ленинград хәрби техник танк училищесына җибәрәләр. Бер елдан ул кече лейтенант-техник дәрәҗәсе ала һәм Владивостокка танкларга каршы сугышучы гаскәрләр сафына отделение командиры итеп җибәрелә. Бу әле 1939 ел гына була. Һәм менә сугыш мобилизациядән соң туган якны күреп сөенү, үзенең җанкай җанашы Прасковьясы белән тәүге тапкыр инде бергәләшеп ир белән хатын булып, алсу таңнар каршылаулары татлы төш кебек кенә сугыш арасындагы тынлык вакытында күз алдына киләләр. Һәм тагын дошман уты. Бомба-миналарның авыр гөрелтесе матур хыялларны иртәнге томандай таратып ташлый.

-Лейтенант Токранов!

Ул үзен рота командиры чакырганын ишетеп тиз генә күзәтү пунктына таба йөгерде.

-Тыңлыйм!

-Штаб начальнигы сезнең взводка әнә теге урманчык читендәге биеклекне сакларга приказ бирде. Беләм, көчләрегез аз. Әмма чигенү дошманга бирелү белән бер. Үтәгез!

Лейтенант үзенең автомобиль взводын күрсәтелгән юнәлешкә таба үткәрә. Сугышчыларга хәлне яшермичә ачыктан-ачык әйтеп бирә. Хәер, алар үзләре моны яхшы аңлый торган кешеләр.

Оборона өчен тиешле урын хәзерләнгәч, И. Токранов туган авылына - Прасковьясына хат язарга утырды.

,, Исәнме, Прасковья матурым!”- дип башлады ул. Менә әле фашист бераз тынып тора. Сиңа хат язам. Бик сагындым, сине дә, авылны да. Мәктәпне сагынам, балалар укыган һәр класс, һәр парта күз алдында...

Дошман озак көттермәде. Нәкъ алар оборона алган якка ротадан артык солдат белән мотоукчылар һөҗүме башлана. И. Токранов солдатлары тешләрен кысып арысланнардай сугыштылар. Беренче һөҗүмне кире кайтарганда ук дошман үзенең утызлап башкисәрен сугыш кырында калдырып чигенергә мәҗбүр булды. Аннан тагын, тагын һөҗүм. Соңгысы инде тәмам хәлсезләнгән, ачыгып, йончып беткән солдатлар өчен аеруча кыен була.

Немец ул көнне иртәдән үк һөҗүм башлый. Токранов взводы бер-бер артлы 3 һөҗүмне кире кайтара. Яралылар кулына корал алырдай һәр кеше дошманга каршы көрәште. Тик оборона сызыгы барыбер өзелә. Кул сугышы башлана. Приказны үтәү армиядә төп закон булгангадырмы яки

туган илгә мәхәббәт хисе шул кадәр көчлегәме, инде тәмам хәлдән тайган солдатлар бу юлы да дошманны чигенергә мәҗбүр итәләр. Тиздән ярдәм дә килеп җитә. Бу сугыш, бу батырлык өчен И.Токранов взводының һәр солдаты - исәне дә, һәлак булганнары да Ватаныбызның бүләкләренә лаек булдылар.

Ленинград блокадасында хәл көннән-көн авырая бара. Көннән-көн шәһәрдә дә, хәрби частьларда да азык-төлек белән эш кыенлаша. Ә дошманның провокацияләре артканнан арта. Нәкъ менә шул чорда Ленинград блокадасына бик күп партия членнары кебек И.Токранов та солдатлар арасында зур тәрбия эше алып бара.

900 көн. Аның һәрбересе сугышчылар өчен авыр сынау көннәре була. Табигатьнең көзге байлыгы - Ленинградны саклаучылар өчен ачлыктан котылуның бер чарасы. Сугыш башланганда әзмәвердәй булган егетләрне дә блокада сулыктырып калдыра. Тик шундый вакытта да И. З. Токранов частендә бер генә солдат та тез чүкми, дошман провокациясенә бирелми. Һәр көн саен дошман явызланганнан-явызлана барып, шәһәргә һөҗүмне дәвам иттерә. Аның ерткычлыклары биредә һәр адым саен онытылмаслык дәлилләр белән билгеләнеп кала...

Ул көнне лейтенант И.Токранов взводына шәһәр тирәсендәге бер участокны саклау бурычы куела. Бу, дошман һөҗүмен кире кайтару гына түгел, шәһәр халкына бәла-каза килсә аларга да ярдәм күрсәтү дигән сүз. Һава һөҗүме башлана. Бомбалар бер- бер артлы кешеләрнең фидакарь хезмәтләре белән төзелгән биналарны юк итәләр. Нәкъ шул чакта аларның берсе узып баручы трамвайга эләгә . И. Токранов берничә солдат белән шул якка чаба. Исән калганнарны тиз генә тыныч урынга күчерә башлыйлар. Шулчак ул бер сабыйның үле әнисенең кулларыннан тотып яшенә буыла-буыла:”Әнием, китик тизрәк, өйгә кайтыйк”, дигәнен күреп сүзсез катып кала. Аннан ул баланы кулына ала да, бөтен солдатлары каршында: ,, Менә шушы ятим калган нарасый өчен, тагын нәкъ менә шундый меңләгәннәр өчен бер үлемгә 2-3 үлем белән җавап бирәчәкбез!- дип ант итә.

Икенче юлы аларга мәктәпкә бомба төшкәннән соң укучыларны коткаруда катнашырга туры килә.

Һөнәре буенча укытучы кешегә мондый күренешләр аеруча нык тәэсир итә, билгеле. Күңелдә туган нәфрәт дошманны тәмам юк итү хисе көннән-көн арта. Блокада өзелә. И.З. Токранов сугыша торган часть Вильнюс юнәлешендә дошманны кууын дәвам итә. Бу чорда яшь лейтенантның күкрәгендә хәрби медальләр белән бергә Кызыл Йолдыз ордены да балкый. Һәм менә күптәнге – Җиңү ! И. З. Токранов яңадан үзе хезмәт чик буе гаскәрләре сафына җибәрелә һәм 1947 елда яз көне туган авылы Иванаевога кайта.

Тыныч тормыш ! Миллионлаган кешенең миллион төрле хыялын тормышка ашырыр вакыт җитте. Тик ул хыяллар да авыр, өзлексез хезмәт, төне-көне тир түгү бәрәбәренә генә тормышка ашалар иде шул.

И. З. Токрановның хыялы балаларны чын кеше итеп тәрбияләү иде. Ул башта укытучы, анан Иванай мәктәбе директоры булып эшли. Райондагы

өлкән укытучылар хәтерлиләрдер, бу мәктәп елның-елында яңа уку елына хәзерлек буенча алдынгылар рәтендә килде. Укучылар белем ягыннан да әйбәт иде.

Тик Иван Захаровичны борчыган бер нәрсә - ул балаларга хезмәт тәрбиясе бирү булды. Ул колхоз правлениясендә дә, мәгариф бүлегендә дә бу мәсьәләне җентекләп аңлатты. Аны хупладылар. Укучылар көче белән берничә ел эчендә менә дигән мәктәп яны участогы барлыкка килде. Озак та үтми, әлеге мәктәптәге хезмәт тәрбиясе башкалар өчен дә үрнәк итеп куелды һәм аны өйрәнергә шактый кеше килде.

Иван Захарович укыту-тәрбия системасының яңалык кертү буенча күп эзләнде, күп укыды. Күп йөрде. Белмәгәнен сорарга оялмады. Шул тырышлык нәтиҗәсе буларак 1961 елда районда беренче тапкыр ул җитәкләгән мәктәптә озайтылган көн группасы оештырылды. Группа өчен ашау-эчү, кирәкле инвентарь алу инде хәзер шактый киңәйгән мәктәп яны участогыннан алган доход хисабыны эшләнде. Авыл халкы бу яңалык өчен И. З. Токрановка аеруча зур рәхмәт әйттеләр, күбрәк ихтирам итә башладылар.

Авылдашларының ихтирамын казану. Аның өчен күп тырышлык кирәк шул, кешелеклелек кирәк. Үзең генә түгел, гаиләңнең дә, балаларыңның да. Иван Захарович Прасковья Матвеевна белән тугыз бала үстерәләр.

... Тормыш дәвам итә. Иван Захаровичның мактаулы эшләрен, тормышның данлы юлын хәзер балалар дәвам итә.

Иван Захарович Токрановны авылдашлары хәзер дә онытмый. Аны һәрвакыт искә алалар, чөнки аның язмышы – сокланырлык язмыш!